# Балыклар.

## *Балыклар нигә суда яши?*

Әүвәл заманда балыклар коры җирдә яшәгән ди. Әллә кайчан инде, әле син өстәл астында бармак суырып утырган чагында ук. Балыклар чирәм чәмченгәннәр, агач башларына менеп алма, җимеш ашаганнар. Урманга җиләккә, гөмбәгә йөргәннәр.

Бу балыкларның бер гадәтләре булган: алар көн дә бәйрәм итәргә яраткан. Өстәвенә бик күп сөйләшәләр ди һәм бер-берсен Дәү балыкка гел әләкләп тә торалар икән. Алар бер-берсен чагудан, әләкләүдән үзләре дә туеп беткәннәр. Тик ничек кенә тырышсалар да, начар гадәтләрен ташлый алмыйлар, ди.

Балыкларның тагын бер начар гадәтләре булган: алар иртән битләрен юарга иренгәннәр. Ә суда коенуга килсәк, яр буена аяк та басмаганнар. Чөнки коенырга уйласаң, өс-башны салырга туры киләчәк бит. Ә алар моңа иренгәннәр.

Бер дә бер көнне Дәү балык Алла бабай янына киңәшкә киткән. Хәлне аңлатып җентекләп сөйләп биргән. Алла бабай боларның барысын да үзе күреп, белеп тора икән.

Ул башкаларны җыеп кисәтү ясаган, ачуланган. Ул ачуланганда бик каты күк күкрәгән, яшен яшнәгән. Балыклар аңа: «Төзәлербез, хаталар башка кабатланмас», дип вәгъдәләр биргәннәр. Әмма бераз вакыт узуга вәгъдәләрен тагын онытканнар.

Алла бабай балыкларга икенче мәртәбә кисәтү ясаган, тегеләре тагын гафу сораганнар. Берара вакыт узгач, биргән сүзләрен янә онытканнар. Өченче тапкырында бабай тагын да ачуланган. Бик каты яңгыр коя башлаган, күк күкрәгән, балыклар су астында калганнар. «Суда гына яшәгез алайса, – дигән Алла бабай аларга һәм, – сөйләшмәгез дә!» – дип өстәгән.

Менә шуннан бирле, балык халкы телсез килеш суда гына гомер кичерә ди. Көн-төн суда булгач, иртән бит юасылары да юк, суда чыланмасын дип өс-башларын да салып торасы юк ди.



# Әүвәл балыклар турында.

-  Әйткәнебезчә, балык тоту җиңел эш түгел. Шуңа күрә аның өчен кармак таягы гына түгел, әүвәл балыкларның үзләре турында белергә кирәк.
- Һәр балык яшәү шартларына карап төрле төстә һәм формада була.
- Суүсемнәрдә яшәүче балыкларның тәннрендә таплар яки аркылы сызык юллар була. Аларны суүсем янында тиз генә күреп алуы кыен. Мондый балыкларга алабуга, чуртан керә. Су өстендәрәк яшәүче балыкларның төсләре якты була һәм алар бик тиз йөзәләр. Тәннәренең өске яклары караңгы, су өстеннән караганда күренмиләр дә. Ә ян -яклары һәм корсакларының көмеш сыман булуы аларны су астыннан караганда күрсәтми. Мәсәлән, чабак .
- Балыклар койрыклары ярдәмендә хәрәкәтләнә.
- Кайбер балыкларга судагы кислородның күп булуы кирәк, ә кайсыберләре исә аз кислород белән канәгатьләнә. Мәсәлән,табан яки кәрәкә (карась) һәм карабалык (линь) суүсемнәр баскан күлләрдә дә яши ала.
- Балыклар уылдык чәчеп үрчи. Һәм шул уылдыклардан нәни балыклар килеп чыга. Нәни балыкның ничек дөньяга килүе суның температурасына бәйле. Җылы суда алар тизрәк үрчи. Мәсәлән,чуртан су җылылыгы 6 градустан ким булмаса гына уылдыгын чәчә, корбанга (лещ) -12 градус, кәрәкәгә 12-14 градус җылылык кирәк.
- Балыкларның күзләре бик яхшы күрә. Шулай ук кайберләренең капшап сизү һәм ис сизү органнары да көчле үскән. Мондыйларга җәен (сом) һәм шулаба яки шалебы (налим) керә. Шуңа күрә кармакка эләктергән җимдә дә, яр буенда да ят ис булырга тиеш түгел.
- Өстәвенә балыкларның колаклары да яхшы ишетә.

# Һава торышы һәм балык тоту

Җәй көне каты җил давыллы көнне, гадәттә, балык эләкми. Алар камыш арасына посып ятәләр. Өстән кояш көчле кыздырганда да балык капмый, алар салкын чишмәләр янынарак китә.

Балык яңгырдан соң шәп каба.

Гадәттә, озакка сузылган начар һава хәлләреннән соң да балык каба башлый.

Җәйге корылык вакытында балыклар су төбенәрәк китә, ләкин анда ризык азрак. Менә шул вакытта балык яхшы эләгә.

Җәй көне кинәт кенә салкын көннәр башланса, балык капмый.

Көзен томанлы иртәләрдә балык яхшы эләгә.

Язгы һәм җәйге томаннар вакытында балык тоту кимесә, томаннардан соң алар яхшы каба.

Җил төньяктан, көнбатыштан һәм көнчыгыштан искәндә балык яхшы капмый.

Әгәр көн болытлы, ләкин җылы һәм җилсез булса, балык яхшы эләгә.

Күргәнегезчә, якты, кояшлы көннәрдә балык капмаска, киресенчә, ямьсез, шыксыз көннәрдә яхшы эләгергә мөмкин. Димәк, балыкларның үз-үзләрен тотышлары һава хәлләренә турыдан-туры бәйләнгән. Шуңа күрә, әгәр балыкка барырга уйласаң, иртәгә көннең нинди буласын алдан белеп торырга кирәк.

Әгәр җил кичкә тынмаса, киресенчә көчәйсә, күктә көнбатыш һәм көньяктан каурыйсыман болытлар агылса, давыл килә дигән сүз.

Җил төньяк-көнчыгыштан булганда матур көн көтелә.

Әгәр каурыйсыман болытлар акрын гына көньяк-көнчыгыштан яки көнчыгыштан хәрәкәтләнсә, яхшы көннәр озак торачак.



# Балыкка җимнәр

Балык кармакка тик торганда капмый. Үзенә ашарга эзләп йөргәндә ялгыш кына йота ул кармакны. Шуңа күрә аңа җимне дә тәкъдим итә белергә кирәк.

**Тирес корты** – каралты-кура яннарында, черегән тирес өемнәрендә, черек саламнарда була. Аркасы куе-кызыл төстә.

**Яфрак асты корты** бакчаларда була. Гәүдәсенең алгы өлеше кызыл-миләүшә төсендә, арткы ягы ачык төстә.

**Җир суалчаны** дымлы урыннарда яши.

**Озын борын личинкасы (мотыль).** Бу озын борыннарның личинкасы. Ачык кызыл төстә була.

**Кырмыска күкәйләре.** Вак балыклар өчен менә дигән җим.

**Чикерткә.** Су өстендәрәк йөзә торган балыкларны чакырып китерү өчен файдаланыла.

**Энә карагы.** Энә карагын көндез тотып булмый, ул бик тиз качып китә.

**Чебен.** Чебенгә чабак кебек балыклар яхшы каба.


**Сөлек.** Сөлекне алабуга балыгы бик ярата.

**Кукуруз.** Балык тоту өчен яшь, әмма катыланып өлгергәне кирәк.

**Борчак һәм ипи** кебек җимнәргә дә балык яхшы каба.



## Корбан балыгы




Корбан балыгы (лещ) елганың кызыл балчыклы урыннарында, тирәндә була. Чиста комлы төшләрдә ул сирәк очрый.

Буалар боздан арынуга корбан балыгын тотарга мөмкин. Ләкин алар май ахырында, июнь башларында тагын да яхшырак эләгә.

Корбан балыгы һава торышына бик сизгер. Һава бозылыр алдыннан аны тоту мөмкин түгел. Аннан соң җил төньяктан һәм төньяк-көнчыгыштан искәндә дә, гомумән, салкын җил искәндә корбан балыгы кармакка капмый. Ул бик сак балык, су өстендә күләгә күрсә дә качып китәргә мөмкин.

## Алабуга



Алабуга (окунь) ел буена каба. Ул җимне шундук, ягъни бик кыю каба.

Алабуганы кармакка агым көчсез булган урыннарда яки бөтенләй тын җирләрдә тоталар.

# Карп балыгы



Карп гадәттә җәй көне яхшы каба. Язлыкта һәм көз көне карпны тотуы бик кыен. Иң яхшы вакыт су ярларына кире кайтып, карплар үзләренең даими яшәү урыннарына урнашкач була. Июнь, июль һәм август— карп иң шәп эләгә торган айлар. Карп яшенле яңгыр вакытында тагын да яхшырак каба.


Су өстенә билгеле бер урынга җим сибеп карпны әүвәл шул төшкә ияләндерергә кирәк. Ул җимне кичтән салсаң да була.

Җим исләнмәгән яки бозылмаган булырга тиеш. Ләкин аны күп сибәргә ярамый, тамагы туйса, карп алдавыч җимгә капмаска мөмкин.

Җим итеп төрле ашлык орлыкларын һәм боткалар файдаланыла. Орлыкны суга коры килеш түгел, парландырып, пешереп салырга кирәк. Шулай иткәндә аның тәмле исен карп әллә кайдан сизеп алачак.

Карпның иң яраткан ризыгы — тары боткасы. Аның да югары сортлысы кирәк.


# Судак балыгы



Судак балыгын каптыру җиңел эш түгел. Гади кармакка аны бөтенләй тотып булмый диярлек. Аны каптыру өчен алдавыч җим итеп вак балыкларны файдаланалар. Чөнки судакның тамагы тар, ул зур балыкларны йота алмый.

Судак балыгын иртән яки кич тотарга кирәк,хәтта төнлә дә эләгергә мөмкин ул. Судак ут яктысын яратмый.

# Шыртлака



Шыртлаканы (ёрш) тирән һәм караңгы сулыклардан эзләргә кирәк. Ул су төбендә үк яши. Шыртлака — ялкау балык, хәтта су өстендәге алдавыч җимгә күтәрелеп торырга да иренергә мөмкин. Аның иң яраткан җиме – тирес суалчаны.

Шыртлака җәй ахырында гына яхшы эләгә башлый. Ул вакытта алар көтү булып йөриләр.

Шыртлака иң тәмле балыклардан санала. Аннан бик шәп уха пешерергә мөмкин.

# Шумба




Шумба (налим) – төнге балык. Ул тамагын су төбендә төнлә генә туйдыра.

Шумба өчен алдавыч җим итеп зур җир суалчанын яки кызыл суалчаннарны файдаланалар. Аларны кармакка баш ягы белән киертергә кирәк. Шулай ук шумбаны ит кисәгенә һәм вак балыкка да тотарга мөмкин.

Шумбаны судан тартып алуы кыен түгел, ул каршылыксыз кармакка ияреп чыгачак. Тик тәне бик шома булганлыктан аны кул белән тотып булмый, шуып китәчәк. Шуңа күрә алдан ук чүмеч сыман җәймә җайланмасын (сачок) әзерләп куярга онытмагыз.

# Табан балыгы




Табан балыгы яки кәрәкәнең (карась) иң шәп эләгә торган вакыты — июнь һәм июль айлары. Бу балык сууcем һәм үләннәр үскән урыннарда яши, чиста суда ул бик сирәк була. Шул рәвешле кәрәкә ерткыч балыклардан да саклана.

Кәрәкәне иртәнге якта тотсаң әйбәт, бигрәк тә сәгать тугыз, уннарга кадәр. Гадәттә кичке якта да.

Кәрәкә өчен алдавыч җимнәрдән тирес корты, ипи катысы файдаланыла.


Җылы, эссе көннәрдә кәрәкәләр көтү булып су өстендәрәк йөзәләр.

## Хариус



Хариусны (бәрде) гадәттә яз көне суалчанга тоталар. Җәй көне ул суалчанга капмый. Ул вакытта хариус нигездә суга егылып төшкән бөҗәкләр белән туклана. Көзлектә исә суалчанга янә каба башлый. Бигрәк тә яңгырдан соң яхшы эләгә.


## Чуртан



Яз көне чуртанны көн озын тотарга мөмкин. Җәй көне иртәнге якта һәм кич белән тотарга кирәк. Ул хәтта төнлә дә эләгә. Көзлектә һәм кыш көне чуртанны көн уртасында эләктерү уңайлы.

Чуртан өчен алдавыч җим итеп вак балыклар файдаланыла. Бу балыкны апрель ахырларында, май башында һәм сентябрь аенда тоту киңәш ителә.

# Ташбаш



Ташбашны (пескарь), гадәттә, кармакка гына тоталар. Аны тоту май аенда ук башлана. Һәм ул октябрьларга чаклы дәвам итә. Аны иртәдән алып кичкә кадәр тотарга мөмкин. Аңа һава торышының нинди булуы әллә ни тәэсир итми, ләкин шулай да ул яңгырдан соң яхшырак каба.

Ташбаш тоту өчен алдавыч җим итеп тирес корты, озын борын күкәе (мотыль) файдаланыла.